**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» февраль, 2026 ел № 60-п

Мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенең кушымта итеп бирелә торган бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карар 2026 елның 1 февраленнән үз көченә керә.
3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының «Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2025 елның 28 гыйнварындагы 47-п карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында http://www.pestreci.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Р. Дәүләтханов

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1633605397

Кушымта № 1.
ТР Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты карары белән
расланган
__.__________ 2026 ел №____

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында 2026 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәт күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| **Хезмәтләрнең исеме** | **Хезмәтләр бәясе (сум)** |
|---|---|
| Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| Мәет җирләү өчен табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2714,38 |
| Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 626,42 |
| Кабер казу һәм күмү | 6337,83 |
| **Барлыгы** | **9678,63** |

Кушымта № 2
ТР Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты карары белән
расланган
__.__________ 2026 ел №____

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында 2026 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәт күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| **Наименование услуг** | **Хезмәтләр бәясе (сум)** |
|---|---|
| **Хезмәтләрнең исеме** | - |
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 504,55 |
| 2. Мәетне кәфенләү өчен | 2209,83 |
| 3. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 626,42 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 6337,83 |
| 5. Кабер казу һәм күмү | **9768,63** |
| **Барлыгы** | |